«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында»Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгының 2026 елның 24 сентябрендәге 70 номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) тәртибе һәм аларны оештыру турында нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерыгы проекты буенча, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Апас, Чирмешән а. п., Багыш, Үзәк урам, 1Б з/у адрес буенча урнашкан кадастр номеры 16:08:200201:787, мәйданы 2022 кв. м булган җир кишәрлегеннән файдалануның Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең универсаль торак зонасында (Ж-У) «Дини йолаларны гамәлгә ашыру», «Дини идарә һәм мәгариф» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гавами тыңлаулар билгеләргә.

2.Гавами тыңлауларны оештыручы составын-оештыру комитетын расларга:

1)Хәсәнов Айрат Мансур улы – Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;

2)Нурмиева Әминә Викторовна кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;

3)Зиннәтуллин Айрат Тәлгать улы -Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге башлыгы, бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты;

4)Шакирова Эльмира Фирдүс кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы;

5)Сибгатуллина Гөлнара Мөсәлим кызы – Апас муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе.

3.Гавами тыңлауларны оештыручыга-оештыру комитетына гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4.Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 21 сентябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Хантимеров Ленар Тәлгать улына йөкләргә.

Башлык А.Г. Җиһаншин